ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 09 2019 г. № 540

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты идарәләре тарафыннан ведомствога карган учреждениеләрнең контракт системасы турында законны саклау буенча сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты идарәләре тарафыннан муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен уздыру регламентын раслау турында» 2016 елның 28 октябрендәге 1520 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 100 статьясын гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты идарәләре тарафыннан ведомствога карган учреждениеләрнең контракт системасы турында законны саклау буенча сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты идарәләре тарафыннан муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен уздыру регламентын раслау турында» 2016 елның 28 октябрендәге 1520 номерлы карарына (алга таба – «карар») түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 2-нче кушымтаның 18 пунктында:

«г» и «д» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) контрактның башлангыч (максималь) бәясен, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контракт бәясен, товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлекләренең башлангыч бәясен, товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлекләренең башлангыч бәясен, товар, эш, хезмәт күрсәтү бәяләренең башлангыч суммасын билгеләү һәм нигезләү дөреслеге;

д) сатып алуларның идентификацион кодлары турында һәм әлеге сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс тәэминаты күләмен арттырмау турында мәгълүматның сатып алуларның план-графикларында, сатып алуларны тормышка ашыру турында хәбәрнамәләрдә, тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләрендә, алар белән контрактлар төзелгән контрактта катнашучылар тарафыннан җибәрелгән контрактлар проектлары шартларында, заказчылар тарафыннан төзелгән контрактлар реестрында булган мәгълүматка туры килүе;»;

1.2. «е» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. «ж» пунктчасында «алар тәкъдим иткән контракт бәясе» сүзләрен «үзләре тәкъдим иткән контракт бәяләре, товар, эш, хезмәт күрсәтү бәяләре суммасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. «к» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1.2. пунктчасы 2019 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
җитәкченең беренче урынбасары Р.И. Беляев

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874